№3
НОЯБРЬ
2023 ЕЛ

# Яшь каләмче

Яр Чаллы шәһәре 40 нчы урта гомуми белем бирү мәктәбе

Уңышлар сиңа Әминә!

## Таныш булыгыз



### Максатым — журналист булу

Мин - Гимазетдинова Әминә Әнвәр кызы, Чаллы шәһәре 40 нчы урта мәктәбенең 11нче "Б" сыйныф укучысы, миңа 17 яшь. Рус мәктәбендә укуыма карамастан, туган телемне тирәнрәк белергә, аңларга тырышам. Буш вакытымда хикәяләр, мәкаләләр, шигырьләр язарга, шулай ук кызыклы шәхесләр белән аралашырга яратам.

Минем максатым — журналист булу. Мин озак вакыт булачак һөнәрем турында уйландым. Ләкин бер мизгелдә мин журналист булырга теләвемне аңладым. Минемчә, бу бик кызыклы һөнәр. Журналист тормышның күп өлкәләрен өйрәнә, көн саен яңалык белән таныша, укучыларга төрле вакыйгалар турында сөйли, аның тормышы кызыклы тәэсирләр һәм танышулар белән тулы. Шулай ук, минемчә, журналист даими үсештә булырга һәм һәрвакыт яңалыклар белән кызыксынырга, гадел булырга тиеш.



Хыялымны тормышка ашыру өчен мин мәктәптә җәмгыять белеме һәм әдәбият буенча имтихан тапшырачакмын. Бу фәннәр миңа бик ошый, мин гуманитар фәннәрне яратам һәм аларны яхшы аңлыйм. Мин үзем теләгән һөнәр иясенә ия булачагыма ышанам.

***Сабак (булган хәл).***

*Безнең мәктәптә бик үзенчәлекле бер малай бар. Ул, сигезенче сыйныфта укыса да, ничектер, акылга сай кеше кебек, һәр дәрестә трай тибеп утыра.*

*Беркөнне шул малай мәктәпкә ябыша торган уенчык (лизун) алып килгән. Ул уенчык тәнәфес саен сыйныф бүлмәсе буенча "очып" йөрде һәм, көтмәгәндә, түшәмгә ябышып калды. Һич кенә дә төшәргә җыенмады. Баштан һәммәбезгә бик кызык тоелды, шыр- шыр көлештек. Илгиз, чүп савытын алып, шуның белән "ябышкак"ны төртеп төшермәкче булды, тик бүе җитмәде. Кыңгырау шалтырады, сыйныф бүлмәсенә укытучы килеп керде. Малайлар, май ашаган мәче кебек, тынып калдылар.*

*Шул вакыттан алып ябышкак уенчык түшәмдә "яши" башлады.*

*Икенче көнне дәрескә кергәндә дә лизун шунда иде. Малайлар, укытучы күрмәсен, дип, куркышып утырдылар. Атна үтте. Дүшәмбе көнне укучылар тагын шул сыйныф бүлмәсенә дәрескә керделәр. Математикадан контроль эш. Сыйныф бүлмәсендә тынлык. Укытучы рәтләр буенча йөри. Ул бер укучы янында тукталды да :-Үзең эшлә!- диде.*

*Укучылар шул чакта түшәмдәге лизунның сузыла- сузыла төшеп баруын күрделәр.Ул нәкъ укытучының башы турысына төшәргә чамалый, бугай. Барысы да "ах" итеп, сулыш алудан туктагандай булдылар... Лизун шап итеп укытучының җилкәсенә килеп төшмәсенме?! Коточкыч тынлык...Барысы да укытучының ачуын көтеп, тынсыз калды... Әмма укытучы тыныч кына: "Бу кайсыгызның эше?" – дип сорады. Берәү дә эндәшмәгәч, сорауны кабатлады.*

*-Сез үз эшегез өчен җавап бирә белергә тиешсез,- дидеНиһаять, гаеплеләрнең берсе: "Мин"- диде. Артына борылып карагач, укытучы: "Тагын кем?"- дип сорады. Башта малайлар үз гаепләрен шунда ук танымадылар, ләкин соңыннан гафу үтенделәр. Бу көнне малайларыбыз, эшләгән эшләрен яшермичә, шунда ук танырга кирәклеген аңладылар. Шул рәвешле укытучыбыз безгә гомер буена җитәрлек сабак бирде.* ***Гимазетдинова Әминә***

***Журналист булырга әзерләнәм....***



*В нашей школе учатся талантливые и разносторонние ребята, которые могут буквально все. И мы с гордостью сообщаем, что у нас начал свою работу медиацентр, а первый наш выпуск посвящен Орлятам России.*
*Репортаж вела ученица 11Б класса Гимазетдинова Амина Анваровна*

# ӘНИЛӘР КӨНЕ БЕЛӘН!

# С ДНЕМ МАТЕРИ!





## КОЯШ ГОМЕРЕ ТЕЛИМ МИН, ӘНИЕМ СИҢА!

Укучым әниләр турында

### Әниләр турында уйлануларым

*Кем дөньяга кеше бүләк итә,*
*Ә кешегә якты дөньяны?*
*Тойгылары кояш кебек кайнар*
*Эретерлек гранит кыяны.*

*Кем күңеле тулган айдай серле*
*Назлар сыман якты, ягымлы?*
*Шатлыкларын башкаларга бүлеп,*
*Кайгыларга түзем, сабырлы?*

*Кем куллары өйне, җирне ямьли*
*Изгелеге үлчәү тапкысыз?*
*Ул, әлбәттә, яшәү чыганагы*
*Тормыш яме- ӘНКӘЙ,*
*ХАТЫН_КЫЗ*

Әни! Әнкәй! Әнием! Әнием – минем иң якын кешем. Әнием миңа гомер бүләк иткән һәм мине көн саен бәла-казалардан, авырулардан саклый торган хатын-кыз. Билгеле, һәркемнең үзен тудырган әнисе бар, алар барысы да төрле. Ләкин, әни нинди генә булмасын, ул безне бу дөньяга китергән хөрмәтле һәм яраткан кешебез!

Әни кеше үз баласына тормышының төрле минутларында ярдәм итә, ул безнең хисләребезгә бик игътибарлы. Минем нинди хисләр кичерүемне, аңардан нәрсә яшерергә тырышуымны аңлау өчен әниемә миңа таба бер караш ташлау да җитә кебек, чөнки әнине алдап булмый, аның йөрәге барысын да сизә! Бу – безнең әниләребезнең үзенчәлеге, алар чит-ят кешеләрнең берсендә дә булмаган сыйфатларга ия – бары әни генә безне аңлый ала! Әниләр безне тәрбияләп, чын кеше итеп үстерү өчен бөтен көчләрен куялар һәм барлык киртәләрне урап узалар.

«Баласы булмаганнар бала тәрбияләүнең никадәр авыр икәнен беркайчан да аңламаслар» – диде бервакыт әнием. Мин, аны ишеткәч, гаҗәпләндем, өстәвенә, башта бу сүзләрнең мәгънәсен аңламадым. Баланы киендерү, ашату һәм юындыру шулкадәр авырмы икәнни? Әйе, шулайдыр. Кечкенә балалар еш кына кәефсез, елак булалар. Әниләргә теләсә нинди авырлыкларны җиңәргә кирәк, ә бу беренче карашка гына җиңел кебек. Нинди генә булсак та, әниебез безне ярата. Ялгыш адым ясасак та, кайвакыт, уйламыйча, әниләребезне рәнҗетсәк тә – безне һәрвакыт кичерә ана йөрәге! Башка кеше безне кичерә алмас иде. Бу – чыннан да зур хөрмәткә лаеклы батырлык.

Гомумән, әниләребезнең батырлыгы турында бик озак сөйләргә мөмкин, аларның безгә булган мәхәббәтен бәяләп бетерү мөмкин түгел. Мин әти-әниләребезгә кадер-хөрмәтне, шулай ук яратуыбызны аңлатырга тырышуны бик мөһим дип уйлыйм.

Әниләребез һәрвакыт хәлебезне белешеп торалар, сорамыйча да, күз карашыннан ук үзебезне ничек хис итүебезне тоялар. Ә без үзебез аларга андый сорауны еш бирәбезме, аларның күңелләрен аңлыйбызмы соң? Юктыр, мөгаен. Бәлки, алар үзләрен ничек яратуыбызны, рәхмәтле булуыбызны ешрак ишетергә телиләрдер. Әниләребезгә телефоннан ешрак шалтырату, кайтып хәлләрен белешү, хәлдән килгәнчә ярдәм итү дә зур шатлык һәм күңел тынычлыгы бирер иде, аларның гомерен озайтыр иде. Аналарга бала тарафыннан шундый игътибар бик кирәк дип саныйм мин. **Гимазетдинова Әминә.**

***Минем әнием.***

*Минем әнием -Алинә Зөфәр кызы. Аңа 32 яшь. Ул гаиләдә 5 нче бала булып туган. Әниемнең чәчләре кара, күзе яшел төстә.Әнием бик уңган. Иртән торуга тәмле коймаклар пешереп, чәйләр әзерли. Ял көннәрендә бәлешләр, өчпочмаклар пешерә. Аның пешергән ризыклары бик тәмле була. Әнием инженер булып эшли. Әни белән әти 11 ел тату булып яшиләр. Безнең гаиләдә бик рәхәт, без барыбыз да дуслар.*
*Мин әниемне бик яратам.*

***Сафиуллин Данис, 4в сыйныфы***

***Кадерле әнием.***

*Җирдә иң кадерле кеше-әни. Әни чын күңелдән безне ярата. Ул безгә ярдәм итә, ялгышларыбызны гафу итә.Әни иң олы йөрәкле кеше.*
*Үсеп җиткәч, без дә аңа булышырга , игътибарлы булырга тиеш. Без әниебезгә бары ягымлы , мтур сүзләр белән генә дәшәргә тиеш. Мин кадерле әниемне бик яратам.*

***Имаметдинов Марсель 4в сыйныфы***



***Кадерле әнием.***

*Минем әнием матур, акыллы, киң күңелле, эшчән. Кич белән мин әни белән дәрес карыйм. Йокларга ятканда мине әни кысып кочаклый, үбә, тыныч йокы тели. Минем әнием тәмле ризыклар: бәлеш, өчпочмак, кыстыбый, мантый пешерә. Ял көне мин әнигә идәннәр юарга булышам. Кич белән төрле уеннар уйныйбыз. Мин әниемне бик яратам .*

***Фазлыева Самира ,4в сыйныфы***



*Минем әнием*

*Әниләр көне иң зур бәйрәм. Әни ул дөньяда иң якын кеше. Алардан башка ашлар да тәмле булмый, дөнья да матур булмас иде.*
*Минем әнием- Динара. Ул акыллы, матур, уңган. Тәмле ашлар пешерә, матур гөлләр үстерә, миңа булыша. Мин дә әниемә булышам.*
*Мин әниемне бик яратам,аңа озын гомер телим.*

***Саттаров Азамат, 4 в сыйныфы***

*Минем әнием*



*Минем әнием бик матур. Мин әниемне бик яратам. Ул өйдә бик күп эшләр эшли, ә мин аңа булышырга тырышам. Без тузан сөртәбез, савыт-саба юабыз. Тузан сөрткәннән соң идәннәрне юып алабыз. Без әни белән урамда һава сулап йөрибез, бергә кибетләргә барабыз. Әнием минем бик уңган, мин аннан үрнәк алырга тырышам. Мин әниемне бик яратам.*

***Гусманова Риана, 4в сыйныфы***

# Җәннәт аналарның аяк астында.



**АНА..**
**Бөек исем!**
**Нәрсә җитә ана булуга!**
**Хатыннарның бөтен матурлыгы,**
**Бөтен күрке ана булуда   ( Һади Такташ)**

*Кадерле әнием.*

*Мин әниемне бик яратам. Минем әнием бик матур һәм яхшы. Ул бөтен гаилә өчен тәмле ризык әзерли. Ул шулай ук тегәргә һәм бәйләргә ярата. Ял көннәрендә без әнием белән урманга чыгабыз. Әниләрне хөрмәт итәргә һәм яратырга кирәк.*

***Гобайдуллина Ләйлә, 4 в сыйныфы***



*Кадерле әнием.*

*Иң кадерле кеше- әни. Мин әниемне бик яратам, һәрвакыт аңа охшарга тырышам. Ул шат күңелле, тыныч, эшчән, тәмле пешерә. Мине дә тортлар, кекслар пешерергә өйрәтә.*

*Әнием ТАИФ та исәп-хисапчы булып эшли. Аны эшендә бик яраталар, хөрмәт итәләр. Аның фотосурәте мактау тактасында тора. Ул үзенең эшен бик ярата.*

*Мин әниемә озын гомер, ныклы сәламәтлек, һәрвакыт матур булып калуын телим. Әнием, бәхетле бул!*

**Фаррахова Алинә, 4в сыйныфы**

***Әнием!***


*Яратам әниемне*
*Моны бар кеше белә,*
*Саулык телим, бәхет телим*
*Яраткан әниемә.*



*Дөньяда иң яхшы әни*
*Беләсезме кемнеке?*
*Белмәсәгез.үзем әйтәм*
*Ул әни бит-минеке.*

*Әни! Шушы кечкенә генә сүздә күпме наз, җылылык сыйган. Алар безнең нәни генә шатлыгыбызны да зур итеп күрә беләләр, кечкенә генә кайгыбызны да уртаклашалар. Әниләр балаларына гел яхшылыклар гына телиләр. Алар җир йөзендә иң әйбәт, иң ягымлы, иң кадерле кешеләр. Минем әнием дә иң чибәр, иң тырыш, бар эшне дә булдыра торган алтын куллы. Ул бәйли дә, тәмле ризыклар да пешерә. Безне дә тәрбияләргә җитешә. Синең өчен шулай кайгыртучы әниең булу-нинди зур бәхет ул! Аны ярату гына җитми. Шуңа да мин аның кадерен белергә, яхшы укырга, тәртипле булырга, ярдәм итәргә тырышам, сеңелләремне карарга булышам.*

***Ибрагимова Самира, 4в сыйныфы***



*Минем әнием.*

*Әни-җирдә иң газиз, якын кеше. Ул сине тудырган, бишектә тирбәткән, синең беренче елмаюыңны , синең беренче әйткән сүзләреңне ишетеп ,тәпи атлап китүеңне күреп шатланган. Без үзебезнең күз алдына да китерә дә алмыйбыз. Алар безнең дөньябызның яме. Һәркемгә үз әнисе дөньядагы иң кадерле кеше. Миңа да үз әнием бик кадерле. Барлык балаларныкы кебек, минем дә телем "әннә "сүзе белән ачылган. Минем әнием бик әйбәт., сабыр, тыйнак кеше.*

***Гаврилова Амира,4в сыйныфы***

*Кадерле әнием.*

*Әни- җирдә иң газиз, якын кеше. Ул сине тудырган, көйләп тирбәткән, синең беренче елмаюыңны ,беренче адымнарыңны күргән. Әни-дөньябызның яме.Әнемне һәм мине әнибез бик ярата. Аның эше дә бик авыр. Ул - укытучы.Эштән арып кайтса да, ул безгә тәмле- тәмле ризыклар пешерә, безнең белән төрле уеннар уйный. ял көннәрендә без бергә урманга, паркларга йөрибез. Әни безне әйбәт булырга, олыларны хөрмәт итәргә өйрәтә, һәрбер уңышларыбызга сөенә. Һәркемгә үз әнисе дөньядагы иң кадерле кеше. Миңа да үз әнием бик кадерле.*

***Мәгъсумов Солтан,4в сыйныфы***



.



*Әни,әнием...*

*Әни тормышыбның иң төп кешесе. Ул баланы дөньяга килгәннән соң иң беренче күргән кеше, һәм ул гына безне беркем дә яратмаган кебек ярата. Ана безгә беренче адымнар ясарга һәм беренче сүзләрне әйтергә булыша. Ул безнең белән тормышның иң авыр минутларында була. Берәр эш килеп чыкмаса, әни төшенкелеккә бирелми.Ул безгә тәмле ризык пешерә һәм бөтен эштә булыша. Без дә аңа гел булышып торабыз. Әни безнең өчен гомер буе үрнәк булып тора. Әнигә бөтен серләремне сөйлим һәм киңәш сорыйм. Әниләр көнендә без аларга матур сүзләрне багышлыйбыз. Бу көн безгә гаиләбезне саклау һәм кадерләү никадәр мөһим икәнен исебезгә төшерә.* ***Васимова Сафира, 9б сыйныфы***

*Әниләр..*

*Кешенең береч сүзе – әни. Дөньядагы һәр бала көненә бер тапкыр булса да бу сүзне әйтә. Күпме әсәр һәм шигырьләр, поэмалар һәм романнар әнигә багышланган. Әниләр безгә тормыш бирәләр. Алар безне беренче минуттан ук үстерәләр һәм кадерлиләр. Безне әнидән яхшырак беркем дә аңламый.Ул иң яхшы ризыклар әзерли һәм акыллы киңәшләр бирә. Ул безне барыбыздан да күбрәк ярата. Әни безне кешелекнең төп сыйфатларына өйрәтә.*

***Галиев Рафаэль, 9 б сыйныфы***







# С Днём матери!

Всех Матерей от души поздравляем, с самым добрым праздником! Несите в жизнь нескончаемый праздник, словно добрые волшебницы, забудьте о бессонных ночах, волнениях, тревогах, отбросьте страхи. Помните вы бесценное сокровище, будьте счастливы, любимы, здоровы, наслаждайтесь и благоухайте, сколько бы не было вам лет.

## *Берегите матерей!*

***Р. Гамзатов***

*Встаньте все и выслушайте стоя*
*Сохранённое во всей красе*
*Слово это — древнее, святое!*
*Распрямитесь! Встаньте!..*
*Встаньте все!*
*Слово это сроду не обманет,*
*В нём сокрыто жизни существо.*
*В нём — исток всего.*
*Ему конца нет.*
*Встаньте! Я произношу его:*
***— М а м а!***

***А. Костецкий***

*Мама...*
*Слов дороже нет на свете!*
*По какой бы ты ни шёл тропе,*
*Мамина любовь над нею светит,*
*Чтобы в трудный час помочь тебе.*
*Мама озаряет сердцем нежным*
*Дни, дороги и дела твои.*
*Оправдай же мамины надежды —*
*Повседневно лишь добро твори!*

Так хочется, чтоб на планете
Всем мамам счастливо жилось.
Всегда чтоб радовали дети,
Чтоб всё заветное сбылось.

День матери — прекрасный праздник.
Всем мамам низкий наш поклон.
Пусть в их глазах сияет счастье,
Пусть будет чистым небосклон.

*Моя любимая мама - самый лучший человек в моей жизни. Она нежная, заботливая и всегда готова прийти на помощь. Моя мама умеет слушать, понимать и поддерживать меня в любой ситуации. Она всегда улыбается и делает мою жизнь светлее. Моя мама талантлива и умеет многое: она готовит вкусную еду и убирается в доме. Я люблю проводить время со своей мамой. Вместе мы занимаемся творчеством и обсуждаем интересные темы. Мама делает мне много любви и заботы, и за это я ей очень благодарен.* ***Юрин Артем, 7а класс***



*Моя мама*



*Мамы - удивительные женщины. Их очень много, но для каждого она одна. Для каждого из нас - наша мама самая лучшая, любимая и дорогая. Моя мама ,конечно, лучшая , но порой она меня пугает. Давайте начнем с не самого хорошего, чтобы закончить позитивом. Мою маму злить нельзя, иначе кончится для вас это плохо. Ее просто не переспорить. И это ее единственный минус. То ,что умеет моя мама, я многое просто не осилю. А именно: готовить, вязать, шить, танцевать. прекрасный садовод, умеет рисовать, вести беседу, является человеком с экономическим образованием, следовательно понимает математику( в отличии от меня), делать сложные прически, знает большое количество литературы, есть чувство стиля в одежде, интерьере и экстерьере, почти психолог. Сама удивляюсь с того, что она умеет. Я вот сейчас сидела писала это, и поняла, что вот моя мама умеет кучу всего. Папа тоже мастер на все руки, мои сестры каждая с высшим образованием, почти теми же умениями ,что и родители, и я! Если из выше перечисленного о маме я и умею то только на 0,1 и на 0,2 максимум. Если перечислить, что умеет мой папа, то будет примерно столько же, сколько и о маме. И процент того, что я умею в папиных умениях будет примерно так же. А у меня ни чувства стиля, ни навыков. Зато пишу каждое сочинение, как войну и мир. Объем почти такой же. Я обожаю своих родителей.*

***Вебер Софья, 7а класс***

***“Яшь каләмче”түгәрәге. Җитәкчесе:Таҗиева Р.Р.***

